СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 18, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 18 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366) 94-2-37, факс (84366) 94-2-37. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Апаз авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 01 » ноябрь 2016 ел** **№ 54**

**Апаз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы нигезендә Апаз авыл җирлеге Советы карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 октябрендәге 87 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Уставына (30.06.2015 №128, 26.10.2015 №9 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**5 статьяда түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:**

- 1 өлешнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, рәсми чаралар үткәрүне оештыру»;

- 1 өлешнең 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, шул исәптән алар урнашкан биналарны (торак йортларны да кертеп), корылмаларны һәм җир кишәрлекләрен карап тоту, тиешле биналарның һәм корылмаларның тышкы кыяфәтенә һәм коймаларын, аларны төзекләндерү һәм үтәү эшләре исемлегенә; биналар (аларда биналар) милекчеләренең һәм янәшәдәге территорияләрне төзекләндерүдә катнашу тәртибен билгеләү; җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнарны һәм йортларның исемнәре белән күрсәткечләр куюны, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм тоту), шулай ук торак пунктлар чикләрендә урнашкан аеруча саклана торган табигать территорияләрендә урманнардан файдалану, аларны саклау, яңадан торгызу».

**6 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 13, 14 пунктлар өстәргә:**

«13) җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау чараларын күрү»;

«14) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.

**11 статья түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:**

«16) гражданнар җыены».

**24 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

"Гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм уздыру тәртибе Татарстан Республикасы законы нигезендә Поселение Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә".

**44 статьяга түбәндәге эчтәлекле 16, 17 пунктлар өстәргә:**

«16) муниципаль берәмлек башлыгы әлеге устав нигезендә муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органын билгели».

17) муниципаль берәмлек башлыгы Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органына, проектның нәтиҗәлелеген бәяләүне уздыру һәм 224-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 2 - 5 өлешләре нигезендә аның чагыштырма өстенлеген билгеләү өчен муниципаль-хосусый партнерлык проектына җибәрә. «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»

**46 статьяның 8 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«8. Җирлек башлыгы урынбасары законнарда билгеләнгән бурычларны, тыюларны һәм чикләүләрне үтәргә тиеш».

**49 статьяда түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:**

- 1 өлешнең 3 пунктындагы 6 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру»;

- 1 өлешнең 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 8 абзац өстәргә:

«җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслый, шул исәптән алар урнашкан биналарны (торак йортларны да кертеп), корылмаларны һәм җир кишәрлекләрен карап тоту, тиешле биналарның һәм корылмаларның тышкы кыяфәтенә, аларны төзекләндерү һәм үтәү эшләре исемлегенә; шул исәптән биналар (алардагы биналар) һәм корылмаларның милекчеләренең якындагы территорияләрне төзекләндерүдә катнашу тәртибен билгеләү; җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне

яшелләндерүне, урамнар исемнәре һәм йортларның номерлары белән күрсәткечләр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту), шулай ук торак пунктлар чикләрендә урнашкан аеруча саклана торган табигать территорияләрендә урманнардан файдалану, аларны саклау, яңадан торгызу».

- 49 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9 пунктча өстәргә:

9) муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә җирлекнең башкарма комитеты түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- муниципаль-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашырганда, җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә;

- муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү төзү хокукына конкурслар уздыру өчен конкурс документациясен гавами партнерга килештерә;

- муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыруны мониторинглауны гамәлгә ашыру;

- муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыру барышында гавами партнерларның һәм хосусый партнерларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауда ярдәм итә;

- муниципаль-хосусый партнерлык турында төзелгән килешүләр реестрын алып бара;

- муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү хакында мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итә;

- муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыру мониторингы нәтиҗәләрен вәкаләтле органга тапшыра;

- 2015 елның 13 июлендәге Федераль законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру. «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 224-ФЗ номерлы, башка федераль законнар, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм норматив хокукый актлары, әлеге устав нигезендә җирлекнең муниципаль хокукый актлары белән.

2. Әлеге карарны, ул кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә, Уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органына җибәрергә.

4. Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге башлыгына уставларны теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан “Апаз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карарны гражданнар күпләп тупланган урыннарда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерү һәм республикабызның хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгару юлы белән бастырып чыгару турында карар кабул итәргә.

5. Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башлыгына уставларны теркәү өлкәсендәге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне рәсми игълан итү чыганагы һәм датасы турында белешмәләр җибәрергә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Садиков